СОВЕТ
НОВОКИШИТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Дружба, д. 100а, с.НовыйКишит,
Арский муниципальный район,
422034

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КИШЕТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Дуслык урамы, 100а йорт,
Яңа Кишет авылы,
Арча муниципаль районы, 422034

Тел. (84366)55-4-42, факс (84366)55-4-42. E-mail: Nvk.Ars@tatar.ru

**19 октябрь 2017 ел** **№14**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы
Яңа Кишет авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**«Яңа Кишет авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләр проектын раслау турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә, тулаем “Яңа Кишет авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү объектларын чиста һәм тәртиптә тотуга бердәй таләпләр билгеләү максатларында Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кишет авыл җирлеге советы:

1. «Яңа Кишет авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең кушымтада бирелгән төзекләндерү кагыйдәләрен расларга.
2. «Яңа Кишет авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 04 апрелендәге 81.1 номерлы Яңа Кишет авыл җирлеге Советы карарын (2014 елның 11 июлендәге 88.1 номерлы үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип санарга.
3. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Яңа Кишет авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставында билгеләнгән тәртип нигезендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм махсус мәгълүмат стендларында әлеге карарны бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгы Т.А.Арсланов

СОВЕТ НОВОКИШИТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ